| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>13.11.2023 | **КАРАР**<br>№78 |

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 20.08.2018 ел, № 156 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 20.08.2018 ел, № 156 карары белән расланган Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 19.09.2018 № 163, 04.02.2019 № 185, 22.03.2019 № 191, 25.07.2019 № 208, 13.11.2019 №225,20.04.2020 № 235 тәге редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) III бүлектә:

11 статьяда:

11.1 өлешне түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт белән тулыландырырга:

«11) муниципаль хезмәткәрләрнең чит ил агенты статусын алуы.»;

11.3 өлешнең беренче абзацын төшереп калдырырга;

11.3 нче өлешнең икенче абзацында сүзләр «, җирлек сайлау комиссиясе аппаратында», «, җирлек сайлау комиссиясе аппаратын» төшереп калдырырга;

12 статьясының 12.1 өлешендә:

2 нче пунктның «а» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» төшереп калдырырга;

2 нче пунктның «б» пунктчасында, «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» төшереп калдырырга;

4 пунктта сүзләр «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен.» төшереп калдырырга;

2) VI бүлектә:

21 статьяда:

21.2 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.2. Алексеевск шәһәр җирлеге Уставы нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлектәге 21.4 өлеш белән тулыландырырга:

«21.4. Муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә

җирле үзидарә органы бетерелүгә яисә җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штаты кыскаруга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә, оешма бетерелүгә йә оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә хезмәткәрләр өчен эштән азат ителгән очракта, хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.»;

22 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 22.3 өлеш белән тулыландырырга:

«22.3. Озак еллар хезмәт иткән өчен пенсия муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән кешедә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда билгеләнә.

Күрсәтелгән бурычның күпьеллык хезмәте өчен пенсия билгеләү өчен мөрәҗәгать ителгән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда, күпьеллык хезмәте өчен пенсия билгеләү шундый билгеләнү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.»;

3) VIII бүлектә:

28 статьяда:

28.2 өлешендә сүзләр «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясен» төшереп калдырырга;

28.3 өлешендә сүзләр «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясен »,
«, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен», төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә .

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары В.В. Увакинага йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр**
**җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**